**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**БОЛЬШЕОШНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422646, с. Большой Ошняк,
ул. Г.Тукая, дом 28а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ ӘШНӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422646, Олы Әшнәк,
Г.Тукай урамы, 28а нче йорт,

Тел.: (84361) 27738, факс: (84361) 27738, e-mail:Bosn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 17 августы** **Олы Әшнәк ав** **№ 9**

Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Башкарма комитетының “2018-2019 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге территориясендә терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау программасын раслау турында " 2018 елның 1 июнендәге 6 номерлы карарын гамәлдән чыгару турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2018 елның 7 августындагы 16086508201800007 номерлы хокукый экспертиза бәяләмәсе нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 7.1 пункты, 3,4 өлеше, 48 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 5 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Олы Әшнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Башкарма комитетының «2018-2019 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге территориясендә терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау программасын раслау турында» 2018 ел, 1 июнь, 6 нчы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28а йорт; Кече Әшнәк авылы, Кызыл Армия урамы, 32а йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге Башлыгы Р.А.Хөснетдинова